**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар Абдул авылы №41 03 октябрь 2016 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Чубар Абдул авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар Абдул авыл җирлеге башлыгының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 14 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдул авыл Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 38 номерлы карарын карап,

Чубар Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чубар Абдул авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез Чубар Абдул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2017 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

1) җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (Чубар-Абдул авылы юлларына вак таш җәю-68,3 мең., вак таш җайланмасы

Буралы авылы юлларын каплау - 56,5 мең, Мәндәй авылы юлларын вак таш белән каплау-38,7 мең), гражданнарның үзара салым акчаларын

163,5 мең сум күләмендә;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис Н.А. Фәтхетдинов